


*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 8, апрель, 2026 ел*



**Ветеран укытучылар белән танышуны дәвам итәбез**

## Сагыева Йолдыз Сибәгать кызы

1927 нче елның 23 нче мартында Әтнә районы Күлле-Киме авылында укытучы гаиләсендә туган.

Әтисе Хәмитов Сибәгать Насибулла улы укытучы булып та, күп кенә җитәкче урыннарында да эшләгән. 1937 нче елда укытучы булып эшләгәндә халык дошманы дип кулга алынып шунда үлеп кала.

Әнисе Саймә Хәеретдин кызы башта укытучы булып эшли. Соңыннан колхозда эшләп пенсиягә чыга.

Йолдыз апа 1941 нче елны Күлле-Киме җидееллык мәктәбен тәмамлый. Сугыш елларында колхозда хисапчы булып эшли.

1945 нче елны Әтнә урта мәктәбен тәмамлап, Түбән Көек җидееллык мәктәбенә татар теле, немец теле укытучысы итеп билгеләнелә.

1946 нчы елны Күлле-Киме җидееллык мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укыта.

1947 нче елның августыннан Күлле-Киме балалар йортында эшли башлый. Анда 3 ел тәрбияче, 1950 нче елның августыннан завуч булып эшли.

1951 нче елны тормышка чыга. 1953 нче елны гаиләсе белән Кавказга китә.

1956 нчы елны Казак Үртәме авылында клуб мөдире булып эшли.

1957-1959 нчы елларда Каенсар башлангыч мәктәбендә укыта.

1960 нчы елны гаиләсе белән Куәм авылына күчеп килә.

1960 нчы елның августыннан 1961 нче елның августына кадәр Куәм балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

1961 нче елның августында Куәм җидееллык мәктәбенә башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп билгеләнелә.

1982 нче елны шул мәктәптә лаеклы ялга китә.

Йолдыз апа – минем беренче укытучым. Минем үз профессиямне сайлауда аның үрнәге һичшиксез беренче. Ул безгә төпле белем бирде, тормышта үз урыныбызны табарга юл күрсәтте. Олы йөрәкле, сабыр, ярдәмчел, бөтен йөрәге белән чын укытучы ул. Аның кебек укытучы булырга тырыштым. Мәктәпне һәм балаларны яраттым. Инде менә 40 ел мәктәбемдә укытучы булып эшлим.

Укытучы – ул якты маяк кебек. Тормышта гел юлны яктыртучы, әйдәп баручы, кирәк вакытта ярдәм кулы сузучы да.

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы, тарих укытучысы**



### Тукайлы яз

Кырлай якларына язлар килсә –
Күңелдә боз ереп кузгала...
Тамчылары чыңлый, тыңлыйм дисәм
Тукай гомер иткән ызбада.
Буламы соң җиһан гүзәлләгән
Тукайлы язлардан ямьлерәк?!
Моңлы тамчылары сөйлән-сөйлән:
Галәмдә иң җырлы шигърият!
Күз яшьләрен түккән яз иртәсе
Ятимдәй Тукайны юксына...
Мәңге мирасын җуймас татарга
Тукайсыз яз һич тә юк сыман.

**Тукай! Ул калдырган иҗат мирасы һәм рухи яктылык безнең горурлыгыбыз. Олы юбилеен белә Тукай әфәнде...**



### Тукайлы яз

Безнең мәктәптә Г.Тукайның тууына 140 ел булу уңаеннан бик күп чаралар булып үтте. Шулар арасында миңа иң ошаганы - инсценировкалар конкурсы булды. Без дустым Райназ белән Г.Тукайның "Кызыклы шәкерт" шигырен сәхнәләштердек. Шигырьнең сүзләрен ятлау миңа бик авыр булса да, тырыштык, өйрәндек. Бу конкурста чыгыш ясау безгә бик ошады, кызлар да киләсе елга катнашырга теләк белдерде. Без башка сыйныфларның чыгышларын да бик ошаттык, аеруча Шүрәлеләр бик кызык һәм куркыныч иде.

**1 нче сыйныф укучысы Эргашов Билолиддин**





## Экологик калейдоскоп

Халыкара жир көне уңаеннан 22 нче апрель көнне классыбыз белән авыл китапханәчесе Луиза апай оештырган экологик чарада катнаштык.Чара барышында Жир көне тарихы турында күп мәгълүмат алдык. Планетабызның матур бай табигате, кеше гаебе белән килеп чыккан экологик проблемалар белән таныштык. Һәрберебез экологик проблемаларны чишү юлларын уйладык,үз фикерләребезне әйттек.

Луиза апай безгә экология темасына "Очты-очты...", "Житез тиеннәр", "Чүпне аерабыз" уеннарын уйнатты. Шулай ук викторина сорауларына да җаваплар бирдек.

Чара ахырында Луиза апай "Жир-уртак йортыбыз" темасына ясаган рәсемнәребезгә нәтиҗә ясады.

**2 нче сыйныф укучысы Абдуллин Ильдар**

## Тукай иҗатында табигать

Тукай иҗаты белән танышкач, шундый фикергә киләсең: шагыйрь – табигать сакчысы. Габдулла Тукай әсәрләрендә табигатькә, аның "тере почмагына" мәрхәмәт иясе тәрбияли. Иң кечкенә балаларга язылган "Бала белән Күбәләк" шигыре балага гомерлек үгет-нәсихәт булырлык. Күбәләк баладан:

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, -
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа! –дип ялвара.

Күбәләкнең бу сүзләре һәркемнең күңелендә калырга тиеш. Шагыйрь шуны тели. Җирнең матурлыгын, һаваның сафлыгын саклау мәсьәләләре бөек шагыйребезне борчыган. Ул бу турыда уйланган, шул хакта күп кенә әсәр иҗат иткән. Шагыйрь фикеренчә, дөнья матур, шушы матурлыкны күп вакыт кеше үзе бетерә. Ул табигатьнең һәртөрле матурлыгын күреп шатлана, аның белән горурлана. Үзенең рухи халәте дә табигатькә бәйле.

Шагыйрьне илһамландыручы да табигать үзе. Туган ягына мәхәббәтне дә Тукай табигатьне сурәтләүдән башлый. Ул эчкән суга зур әһәмият бирә. Кешенең бөтен гомере су белән бәйле. Бер "кечкенә генә инеш" ("Шүрәле") бөтен авылны саф су белән тәэмин итеп тора.

Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән. ("Туган авыл")

Г. Тукай үз ягының урманнарына чын күңеленнән гашыйк. Ул яхшы белә: урман саф һава чыганагы да, бетмәс-төкәнмәс байлык та. Аның фикеренчә, урман – саулык, байлык сандыгы. Г. Тукай табигатьнең һәр фасылын, һәр мизгелен үзенчә күрә. Аны табигатьтәге үзгәрешләрнең кеше ихтыярыннан тыш булуы шатландыра. "Жир йокысы", "Яз галәмәтләре", "Валлаһи", Буран", "Яңгыр", "Яз хәбәре", "Елның дүрт фасылы" шигырьләрендә автор кабатлан-мас бизәкләр белән бөтен табигать мизгелләрен күз алдында җанландыра. Г. Тукай үз иҗатында табигатькә ямь өстәүче, аны җанландыручы кошларга да зур урын бирә, "Карлыгач","Карга", "Кошларга", "Кошчык", "Күгәрчен", "Фатима белән Сандугач" шигырьләре аша шагыйрь балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди. Шагыйрь хайваннар дөньясына да битараф түгел. Аларны ул дуслары, ярдәмчеләре дип саный, һәркемгә билгеле булган "Гали белән Кәҗә" шигыре үзе генә чын дуслык үрнәге булып тора. Табигатьтәге көчсез хайваннарны кызгана шагыйрь, кешеләрне бәгырьсезлектә гаепли. Г.Тукай табигатьне ярата, аның һәр күренешенә, җан иясенә саклык белән, яратып карый. Кешеләрне дөрес яшәргә чакыра.

Бөек шагыйребез "әйләнә-тирә мохитне саклау" фәнен өйрәнмәсә дә, яшәү йортыбыз булган Жир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Кеше табигатьне яратырга, сакларга, аның белән хозурланырга, аның кочагына омтылырга тиеш. "Туган җиремә" шигырендә Казан артын яратып искә ала, искиткеч табигатен тасвирлый, туган җирем җаныма ягымлы дия. Инеш һәм чишмәләре кырлары үзәннәре матурлыгын сөйли. Әйе, без Тукайны өйрәнәбез, аңа сокланабыз, иҗатына баш иябез. Мин дә авылым табигатенә сокланып карыйм. Тукай безнең Каенсар авылына да кунакка кайткан. Табигать матурлыгы беркемне битараф калдырмый. Туган җиребез, сулар һавабыз чиста булсын. Тау башына салынгандыр безнең авыл, бер чишмә бар якын безнең авылга ул........... Бу шигырь менә безнең Каенсар авылына атап язылган кебек. Мин авылымны, аның табигатен бик яратам.

**6 нчы сыйныф укучысы Галявиева Алия**



## Планетабыз безнең кулларда...

22 нче апрель – Бөтендөнья жир көне. Бу көнне һәр кеше җир шарын саклауга өлеш кертергә бурычлы. Урманнарны, сулыкларны, үсемлекләрне , тере җан ияләрен саклау бездән тора. Табигать безнең ялауга мохтаҗ. Әйдәгез, чисталыкны саклыйк! Киләчәккә табигатебез тагын да безгә бик күп файда китерсен, саф һавалы җирдә яшик.



## Кәҗә белән сарык сәяхәте

Апрель аенда татар халкынының яраткан шагыйре Габдулла Тукай туган. Быел бөек шагыйребезнең тууына - 140 ел. Шул уңайдан без, 4 нче сыйныф укучылары, Г.Тукайның “Кәҗә белән сарык”әкиятеннән өзек сәхнәләштердек. Әти-әниләребез безгә әби, бабай, кәҗә, сарык рольләренә киемнәр табарга булыштылар. Сыйныф җитәкчебез ярдәме белән без бик тырышып әзерләндек. Нәтиҗәсе куанычлы булды. Без “Тукайлы яз” иҗади эшләр бәйгесенең инсценировка номинациясендә 2 нче урын яуладык.Шулай ук Тукай иҗаты буенча рәсемнәр һәм кул эшләре дә ясадык. Кыскасы,без Тукайның иҗатын яратып өйрәнәбез.

**Халитова Иркә, 4 нче сыйныф укучысы**



## Туган телем –иркә гөлем

Тукайның туган көнендә республикабызда тагын бер гүзәл бәйрәм уздырыла: ул да булса – Туган тел көне. Әлеге ике бәйрәмнең бер көндә үткәрелүе очраклы гына түгел, чөнки Тукай һәм туган тел ул аерылгысыз, алар бер-берсенә үрелгән язмышлар, үткән белән киләчәкне тоташтырып торучы күпер дисәк тә ялгыш булмас.

Халкыбыз “Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр” дигән. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк, чөнки милләтнең яшәешендә туган тел иң мөһим урыннарның берсен алып тора!

Безнең мәктәбебездә дә Г.Тукай туган көненә бик күп чаралар үткәрелде. Без, укучылар, барсына да бик теләп катнаштык. Ясалма интеллект ярдәмендә видеолар эшләү аерым ошады. Авыр булуга карамастан, кызыклы һәм мавыктыргыч иде.

**Шигапов Фәнил, 10 нчы сыйныф укучысы**

## 26 апрель - Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көне!

26 апрель - татар дөньясы өчен истәлекле дата, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне.

26 апрельдә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көнендә, татар халкы Туган тел көнен билгеләп үтте.Башка бәйрәмнәр һәм истәлекле даталар белән беррәттән, бу көн һәркайсыбызның күңелендә аерым урын биләп тора. “Туган телеңне онытсаң, рухыңны югалтырсың…”– дип язган шагыйрь. Туган телен белмәгән кеше үз халкыннан да, милли тамырларыннан да аерыла, туган җиренә дә ят була. Без күпмилләтле илебездә төрле телләрнең һәм үзенчәлекле диалектларның байлыгын һәм аһәңен саклап калырга тиешбез. Туган тел көне һәрвакытта да тынычлык, дуслык һәм татулык бәйрәме булсын.

**Хафизов Ислам ,11 нче сыйныф укучысы**



## Бердәмлектә көч

22 апрель көнне «Куркынычсызлык тәгәрмәче»нең район этабы булып узды. Ярышка 11 мәктәптән юл хәрәкәтенең 2-5 нче сыйныф укучылары килеп, үз көчләрен сынап карадылар. Бу ярышка без, 3 сыйныф укучылары да, быел беренче тапкыр катнаштык. Биредә укучыларның юл йөрү кагыйдәләрен белүләре тикшерелде, мәктәп белән өй арасындагы маршрутны күзаллап, имин йөрү кагыйдәләре үтәлеше барланды, беренче ярдәм күрсәтү күнекмәләре дә тикшерелде һәм, әлбәттә, сәпидтә фигуралы йөри белүләре дә иң мөһим пунктларның берсе булып торды. Бу сынау безгә бик кызыклы булды. Чөнки үз күзең белән күреп эшләп карыйсын.Башка җирдә бар әйбер дә безгә яналык булып тоелды. Ләкин без сынатмадык. ЮИД түгәрәгендә алган белемнәрне кулландык. Ә иң күңеллесе сәхнәдә чыгыш ясау. Быелгы ярыш Дәүләт автоинспекциясе оешуга 90 ел тулуга багышланды. Безнең команда бүләксез калмады. “Иң музыкаль” команда исеменә лаек булдык.

**Рашидова Сабрина, 3 нче сыйныф укучысы**



## Гаилә белән бергә

11 апрель көнне без, 3 сыйныф укучылары, һәм әниләребез, укытучы апабыз Римма Нурмөхәммәтовна катнашында республикакүләм “Ата-аналар саклану өчен” конкурсында (Лаеш районы Державин исемендәге күп профилле мәктәптә) район данын яклап лаеклы чыгыш ясап кайттык. Бу конкурс юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәүне өйрәтүне, юлларда игътибарлы булуны максат итеп куя. Әниләребез белән ясалган чыгышларыбыз бик матур булды. Чөнки без бик югары әзерлек белән бардык. Әле чыгыш кына түгел проект эшен дә якладык. Без үзебезгә бик күп яналык алдык. Башка мәктәп укучыларының чыгышларын карадык. Киләчәктә дә андый ярышларда тагы катнашырбыз дип өметләнәбез.

**Низамов Альберт, 3 сыйныф укучысы**